




# Тукай эзләре буйлап…

Гамбарова Гөлсимә Рашитовна
Куныр балалар бакчасы
Уртанчылар төркеме

*Тукай биографиясе — дөнья әдәбияты тарихындагы иң драматик биографияләрнең берсе. Шагыйрь узган юл озын түгел. Аның төп урыннары Кушлавыч — Кырлай — Өчиле — Казан—Уральск, яңадан Казан...*

*Ләкин шул авыллар, шул шәһәрләр арасында күпме фаҗига!*







Өчиле, Сасна авыллары

Мөхәммәтгариф улы Габдулла Тукаев элекке Казан губернасы Мәңгәр волосте Кушлавыч авылында мулла семьясында туа.Габдулла биш айлык чакта әтисе үлә. Шуннан кулдан-кулга, авылдан-авылга. Ятимлекләр, фәкыйрьлекләр, кимсетелүләр..



**Әтисе Мөхәмәтгариф**



**Әнисе Мәмдүдә**



# Кырлайда…



1892 елның июнендә малай Кырлай авылына, Сәгъди абзый белән Зөһрә апа гаиләсенә килеп керә. Кырлайдагы тормышы яшь Тукайның күңелендә иң жылы истәлекләр калдыра.







*Соныннан ул Кырлай авылындагы яшәешен «Шүрәле» (1907) поэмасында, «Исемдә калганнар» дигән истәлекләрендә тасвирлый.*

# Кырлай музеенда







# Җаектә

1895 елда Габдулла Җаекка, Уральск шәһәренә әтисе ягыннан туган Газизә апасы һәм аның ире Галиәсгар җизнәсе янына күчеп килә. Киңрәк дөнья. Татар арасы гына түгел, казакъ, рус арасы да. Типография эшчеләре. Мәдрәсә янында рус классы...



Габдулла Газизә апасы белән

# Казанда...

**1907 елның көзендә Тукай Казанга кайта. Монда ул фикердәшләре һәм мәсләктәшләре Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал белән якыннан таныша, алдынгы фикер ияләре, язучылар, журналистлар, артистлар белән аралаша.**







Габдулла балалык чорында байтак михнәтләр күрә, шуңа да саулыгы нык какшаган була.1910 елда ул үпкә чире белән интегә башлый. Шагыйрьнең саулыгы көннән-көн начарлана бара.





1913 елның 2 (15) апрелендә Казанның Клячкин шифаханәсенә бөек шагыйребезнең йөрәге тибүдән туктый.

